# БЕР МАНЗАРӘ

Үзләренең күптәннән бирле көйли торган көене өзүләреннән риза булмаган кеби, атлар, туктап, кыңгырауларын ачулы гына шылтыратып куйдылар. Уртадагы ат та, бөтен тәнене ак киндер белән япкан кеби бизәкләнгән бәзләрдән аерылыр өчен бөтен әгъзаларын хәрәкәткә китереп куйды. Тагы кыңгырау шалтырап китте. Яндагы ат та керфекләренә каткан карлардан азатланыр өчен тырышып-тырышып башыны җигәннең каешларына ышкый башлады.

Битләре, башлары карга буялып, әллә кая кар каткан, керфекләре артындагы күзләреннән бернәрсәсе күренми торган Әхмәди абзый да, ат башыннан сикереп төшеп, зур бияләйләр белән чикмәнен кага башлады; зур гына сакалыны, нечкә генә мыегыны, озын керфекләрене вә йөзләрене әрчи башлады. Бозлар, бик күп торырга ниятләнеп куйган кеби, мыеклар, сакаллар, керфекләрдән аерылмас өчен бунларның ярдәмнәренә сагынып, анларга чынлап ябышкан кеби, һәрберсе чеметтерә торган авырту белән әле сакал бөртеген, әле мыек бөртеген үзләре берлә алып чыктылар.

Әхмәди абзый, күзләрен арчып бетереп як-ягына карагач, чананың артында, сарык толып, тәвәккәл бүрек киеп, битләренә, муеннарына шарф ураган яшь муллага күзене салды. Аның кара тәвәккәл бүреге, шарфы, тар гына иттереп толып якасына токан камасы, яңа гына чыгып килә торган куе гына мыегы, сирәк кенә чыккан коңгыртрак сакалы, дугаланып, матурланып торган кашы, озын керфекләре — һәммәсе дә бергә тоташып кар белән капланганга, ул яшь мулланың ялтыравыклы күзене дә, түгәрәк кенә, матур гына авызыны да күрә алмады. Ул бераз карап торганның соңында, яшь мулланың кыймылдамавыннан йоклаганына хөкем итеп: «Мулла! Мулла!» — дип аны уята башлады. Чана башындагы кешедән битәр карга манган букчага охшаган мулла селкенә башлады. Ул, дүрт аягыны да бәйләп, кыркырга салынган сарык кеби, үзенең шулай җепләр белән бәйләнеп хөррияте алынуына риза түгеллегене белгертер өчен бөтен көче белән тыпырчынырга теләсә дә, шәфкатьсез җепләрнең ирексез итүенә аптырап калган кеби, бу да

үзенең бөтен тәнене, бөтен әгъзасыны баса торган авыр толыплар, чорналган юрганнар, астка батып төшкән урыннарга каршы бер эш эшләргә көче юк кеби икәнене белеп, бөтен көче белән селкенә башлады. Кулы белән өстендәге юрганыны алып ташламакчы булып, аны өстери башлады. Шул уенны фигълияткә чыгарыр өчен йокыдан яңа гына уянган күзене ачты, керфекләренә каткан бозлар ярыгыннан аңар аз гына якты күренде. Ул чынлабрак карап таң атканмы, юкмыны белергә тырышса да, аны да аера алмагач:

— Әхмәт абзый, таң аттымы? — дип сорады. Авызының селкенгән вакытында ул мыегының, сакалының, шарфының, толып якасының җыенысының бергә ябышканын хис итеп бетерергә өлгерә алмады, су астыннан чыккан кеби гөрләп килә торган үзенең тавышы үзенә ишетелде. Ул үзенең сакаллары, мыеклары, толыплары, шарфларының бергә кушылулары хакында уйларга тотынды. Мәдрәсәдә һәрнәрсәгә үзенчә мәгънә бирергә өйрәнгән башы бу мыеклар, сакаллар, толып карларының һәммәсене дә шәкертчә «мәҗмуг мин хәис мәҗмугка» санап, шул «мәҗмуг мин хәис мәҗмуга»сыны алып ташлыйсы, үзене шулардай азат итәсе килде, ул тагы селкенде.

Әхмәди абзый мулланың тора алмаганын белеп, аны юрганнарыннан аерып, торырга ярдәм итте. Мулла торып басты. Аның бөтен тәненнән әллә нинди электрик тогы кеби бер салкын агу үтте. Ул Әхмәди абзыйның ярдәме белән чанадан чыгып, сакалларыны, мыек-ларыы, толыпларыны берсеннән берсен аера башлады. Күзләре янына өелгән карлы тауларны йимерә башлады. Әхмәди абзый аның өстендәге карларыны кага башлады. Уртадагы ат, тагы селкенеп, кыңгырауны шылтыратып куйды. Мулла карлардан котылып күзләрене ачып карады. Аның күзләренә җәй көннәрендә су буйларында агартыр өчен яшел чирәмгә җәелгән [җитен] кеби сузылып ята торган, борылып-борылып киткән тар гына юл күренде. Аның озынлыгы, аның күзеннән дә югалып урманга кереп китүе муллага мәдрәсәдәге кичә генә монзарә кылышкан тәсәлселне хәтеренә төшерде. Ул: «Әйе, тәсәлсел шулай тезелеп китә, ләкин тәсәлсел илә гайре-л-ниһайә китә, бу юл бер авылга барып

терәлә, — юл гына инде», — дип куйды. Һәм дә үзене алырга килгән Әхмәди абзыйның шул тәсәлселне белмәвене хәтеренә китереп, эченнән генә аннан көлеп, маякларга карый башлады. Алар җәй көне умарта капкачына сарган ил кеби ботакларына сырылган карлар белән матурлануларына һаваланып караган кеби, бунарның карга батып бетүләреннән көлгән кеби булды.

Ул анлардан күзләрене алып алга таба карый башлады. Аның күз алдына ерак кына бер йирдә әллә нинди кар өемнәреннән төтен чыкканы һәм дә шул төтеннәрнең бик һаваланып кына югарыга таба менеп-менеп китүләре күренде. Ул авылны күрә, ул төтеннәрнең чыга торган йирләре буннан кар өеме булып күренсә дә, кар өеме түгел, өйләр икәне һәм дә җылы өйләр икәнлеге хәтеренә төште. Аның бөтен тәннәре шул җылы өйдә буласы килә, шул җылы өйнең түрендә утырасы килә, шул миче чытыр-чытыр итеп яна торган өйнең сәкесендә зур самавыр янында тәмле кайнар чәй эчәсе килә башлады. Ул шул уйга туктап:

— Әхмәди абзый, бу авылга керәмезме? — диде. Әхмәди абзый шул арада атларының күзләре янындагы боз борчакларын әрчеп маташкан йиреннән борылмыйча гына:

— Хода язса, керермез, — диде. Әхмәди абзыйның бу сүзе мулланың укыган тәкъдир мәсьәләсене хәтеренә төшерсә дә, ул аның башыннан бик тиз үтеп китеп, баягы чәй янына барып, андагы самавырны, янына кайнар коймак, бер савыт балны китерү уе белән мәшгуль булды. Ул күптәннән бирле шундый хыялый уйланулардан ләззәт алганга, хыялы бай булулардан шатлык күргәнгә, хыялый ашлардан тук булган кеби булып киткәнгә, бу хыялый кайнар коймаклы кайнар чәйдән дә җылынып киткән кеби булды. Аның яшь күңеле чәйдән соңгы нәрсәләрне уйлый башлады. Өй хуҗасының кызы булуыны, кызының матурлыгыны, шуны күрүен булган кеби иттереп куеп фаразга чумды.

Ат яныннан килеп йиткән Әхмәди абзыйның:

— Иртә намазга өлгерә алсак ярар иде, — дигән тавышы аның фаразын бүлде. Ул:

— Атларны куа төшәргә кирәк, өлгерермез, — диде, һәм дә күзе белән төтен чыга торган йирдән манара эзли башлады. Әллә ничә биегәеп-биегәеп, кардан туннар киеп тора торган кое сиртмәләре арасында ул кар белән өртелгән җуан гына бернәрсә күрде. Күтәрелеп йитмәгән караңгылык, ансыз да җуан манараны тагы бер кат караңгылык белән каплап, аны бик дорфа, бик иләмсез кеби күрсәтте. Мулла, күзене бик озак текәп карап торып, минем дә үз мәхәлләм бар, үз мәсҗедем бар, дип уйлый башлады. Уен сузарга өлгерә алмады, Әхмәди абзый:

— Утыр, мулла! — дип, аның урныны рәтли башлады. Мулла утырды, атлар кузгалды. Ике кыңгырау да берсеннән-берсе калышмаска тырышкан кеби тырышып, шалтырарга тотындылар. Чана, юлның әле бер ягына төшеп, әле икенче ягына төшеп, шул кар диңгезендә йөзә башлады. Аның тулкыннары белән бер менеп, бер төшеп, бормаланып-бормаланып теге төтеннәр, теге өйләргә таба чаба башлады.

Менә үрне төшә башладылар. Әхмәди абзый озын иттереп «хай, әләләләлә!» дип кычкырып, озын чыбыркысыны бутап куйды. Атлар тагы куәтләнделәр, кыңгыраулар, кызулык белән сүзенең яртысыны гына әйтеп сөйли торган кеше шикелле, тавышларының яртысында гына булып кала башладылар. Мулланың битенә коры кар җиле килеп-килеп бәрелеп аның салкын битене кытыклый башлады. Һавалы маяклар берәм-берәм бунларның артларыннан кала башладылар.

Менә кинәттән кеби бунарның күз алдыларына карларга өртелгән агачлар, карлар белән басылган буралар, сирәк-сорак кына кардан башын гына күрсәтеп тора торган ташлар белән тулган зиярәт күренде. Бунарның моң агачлары, карга буялган буралары, кар астыннан кашын тыккан ташлары — һәммәсе мулладан дога көтәләр, Коръән өмет итәләр кеби күренде. Шул яшел ташның бизәкләре, шул яшел наратның кардан курыкмый торган яшел яфраклары, шул кунарга да урыны юк ялангач язьікның күккә таба караган очлары һәммәсе дә: «Йә, яңа мулла, безне дә онытма!» — дигән кеби булдылар. Ул бунарның күңелләрен тутырыр өчен кеби акыртын гына тавыш

белән Коръән укырга тотынды. Әхмәди абзый карт колаклары белән бик ихлас белә тыңлый башлады. Атлар да шуны тыңлаган кеби чабуларыны акрынлаттылар. Кыңгыраулар да шул тавышның тулмаган йирләрене тутырыр өчен кеби моңлырак иттереп сузыбрак шалтырый башладылар. Чана да инсафка килгән кеби юлның әле бер тарафына, әле икенче тарафына сикермичә, уртадан гына, моң гына сызгырып бара башлады.

Коръән бетте, дога кылды. Әхмәди абзый тагы «әй-яй!» дип кычкырып чыбыркысыны бутый башлады. Тагы атлар күтәрелеп киттеләр, тагы кыңгырау тавышыны бозды, тагы чана, юлдагы бер кагылмасын да калдырырга кызганган кеби, әле бер якка, әле бер якка сикерә башлады. Мулланың битенә тагы салкын җил, коры кар сибелә башлады. Төтеннәр якынлашты, тәрәзәләрдән гөрләп яна торган мичләрнең уты күренә башлады. Колакка абзардагы мөңри торган сыер тавышы, әллә кайдан кычкыра торган кәҗә тавышы ишетелде. Атлар туктады.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Фигълияткә чыгару* — эшкә арышу.

*Мәҗмуг мин хәис мәҗмуг* — көтмәгән җирдән җыелган җыелма.

*Тәсәлсем* — бер –берсенә өзелмичә тагылып бару.

*Илә гайре –л – ниһайә* — чиксказлеккә юнәлгән.

*Тәкъдир* — язмыш.

**Бер манзарә** — Хикәя «Аң» журналының 1913 ел 16 (2 август) санында басылып чыккан.

*Языкның* — гөнаһлының (Г.Исхакый биредә наратны кызганып сөйли).

*Кагылма* — кышкы юл кырыеның чана читкә тайпылудан ясалган авыш урыны, бозылган урыны; салу.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:

Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.220-224.